ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ УРЫССУ БИСТӘСЕ СОВЕТЫ

# КАРАР № 15

Урыссу бистәсе 30 сентябрь 2019 ел

Шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрүне билгеләү турында

2002 елның 12 июненнән “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында”гы 67-ФЗ санлы Федераль законның 15 маддәсе, 2003 елның 6 октябреннән “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 22, 56 маддәләре, 2004 елның 25 мартыннан “Җирле референдум турында”гы 23- ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 12 маддәсе, шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Уставының 12 маддәсе нигезендә, 2019 елның 27 сентябреннән “Референдум үткәрүне башлап җибәрү турында»гы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе советының 14 санлы карары нигезендә, Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. 2019 елның 24 ноябренә шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2020 елда шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларга тиңләштерелгән затлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия армиясе сафларында хезмәт итүчеләрнең, 1 һәм 2 төркем инвалидларыннан, балачак инвалидларыннан тыш) 400 сум, көндезге бүлектә укучы студентлардан 200 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләргә тотарга сез ризамы?

1. Урыссу бистәсендә тротуарлар төзү һәм үзгәртеп кору эшләрен башкаруга:
- Ютазы тыкрыгы;
- Жуков урамы;

- Төньяк проезды, Көнчыгыш урамыннан Фәнис Каримов урамына кадәр;
- Көнчыгыш урамыннан Г.Камал урамына кадәр;
- Славян тыкрыгы;
- Чкалов урамында чиркәүдән алып 33 санлы йортка кадәр;
- Урыссу урамында «Олимп» спорт комлексыннан алып «Горизонт» сәнәгать паркына кадәр.

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтына урнаштыру юлы белән кабул ителгәннән соң биш көн эчендә игълан итәргә.
4. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Урыссу бистәсе башлыгы урынбасары,
ТР Ютазы районы Урыссу бистәсе
советы рәисе урынбасары Р.М. Гарипов